**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ТЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423732, село Тюково, ул.Ленина, дом 61/2, Тел. 3-44-61Email: tuk-akt@yandex.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮКЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423732, Түке авылы, Ленин ур., 61/2 нче йорт. Тел.3-44-61

Email: tuk-akt@yandex.ru

КАРАР

21 ноябрь 2023 ел №17

Актаныш муниципаль районының "Түке авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Актаныш муниципаль районының "Түке авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Прокурорның 30.06.2023нче елгы 02-08-02-2023 номерлы протестын үтәү йөзеннән, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 01.04.2022 №90-ФЗ, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 10.07.2023 № 286-ФЗ Федераль законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Актаныш муниципаль районының "Түке авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Актаныш муниципаль районының "Түке авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә , Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Советының 2015 елның 12 гыйнварындагы 3 номерлы карары белән расланган (2021 елның 7 июнендәге 12 номерлы үзгәрешләр кертелгән):

1.1. 16 нчы пунктның икенче абзацында "яисә алар тарафыннан тулы булмаган яисә дөрес булмаган мәгълүматлар тәкъдим итү" дигән сүзләрне "үз чыгымнары турында белешмәләрне, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, тулы булмаган мәгълүматларны белә торып тапшыру, яисә дөрес булмаган мәгълүматларны белә торып тапшыру" дигән сүзләр белән алыштырырга , “яки хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүматны тәкъдим итмәү яки тәкъдим итү " дигән сүзләрне “яки федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүмат бирмәү, тулы булмаган мәгълүмат бирү яки хатыны (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында дөрес булмаган мәгълүмат бирү” дигән сүзләр белән алыштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 6 нчы пунктының «в» пунктчасында һәм 13 нче пунктында "акцияләр" сүзен алып ташларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында "Түке авыл җирлеге"бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

Совет башлыгы: Р.М.Нуртдинов